| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР №4**

**От 01.11.2024**

**Илексаз авылында халык җыенын билгеләп кую турында**

**Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге**

**2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы" Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар:

1. ТР, Сарман муниципаль районы, Илексаз авылы, Комсомол урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан Илексаз авылы мәдәният йорты бинасында 2024 нче елның 15 нче ноябрендә 12.00 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Илексаз авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2025 елда үзара салым кертүгә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, 90 яшькә житкән ялгыз өлкән гражданнардан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасыннан тыш, 2025 елда үзара салым кертүгә 450 сум күләмендә риза буларсызмы:

1) юл корылмаларын буяу өчен буяулар сатып алу, Илексаз торак пунктына юл тамгасы салу;

2)Илексаз авылы, Яшьләр урамы, авыл җирлекләре эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш ташу), күрсәткеч такталар, аншлаглар өчен материаллар сатып алу Илексаз авылында;

3) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (Илексаз торак пунктында махсуслаштырылган техникага - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

4) Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (Илексаз авылында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу); Илексаз т.п.

6) янгын куркынычсызлыгы өчен җайланмалар сатып алу (мотопомпа өчен запас частьләр, сулык өчен материаллар сатып алу);Илексаз т. п.;

7) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтләре өчен түләү);Илексаз т. п.

8) Илексаз т. п. массакүләм ял итү урыннарын ремонтлау (материаллар сатып алу) ;

9) Илексаз т. п. һәйкәлләрен ремонтлау (материаллар сатып алу)

«КАРШЫ» «РИЗА»

3. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 7 көн дәвамында.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы Ф.М.Гильфанов

Илеказ авыл җирлеге башлыгы